ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында” 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4; 2016, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның икенче җөмләсендә “тәэмин итү бурычларын гамәлгә ашыруда һәм җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрне хәл итүдә” сүзләрен “һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү бурычларын гамәлгә ашыруда, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауда” сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итүгә һәм җәмәгать иминлеген, шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шулай ук хокук бозуларны профилактикалауга;”;

б) 2 өлешнең 1 пунктында “җәмәгать тәртибен” сүзләреннән соң “, җәмәгать иминлеген” сүзләрен өстәргә;

3) 7 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктта “һәм җирле әһәмияттәге башка мәсьәләләрнең” сүзләрен “, җәмәгать иминлегенең һәм хокук бозуларны профилактикалауның” сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктта “җәмәгать тәртибен” сүзләреннән соң “һәм җәмәгать иминлеген” сүзләрен өстәргә;

в) 6 пунктта “вәкаләтле участок полициясе хезмәткәрләренә” сүзләреннән соң “һәм эчке эшләр органнарының (полициянең), башка хокук саклау

органнарының бүтән хезмәткәрләренә” сүзләрен өстәргә;

4) 8 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында “җәмәгать тәртибен тәэмин итү мәсьәләләре” сүзләрен “җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре, тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлегенең башка мәсьәләләре” сүзләренә алмаштырырга;

5) 9 статьяның 2 өлешендә “җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыру мәсьәләләре” сүзләреннән соң “һәм җәмәгать иминлеге мәсьәләләре” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 09 март
№ 9-ТРЗ